**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, майдан Советы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**« 17 » сентябрь 2024 ел** **№ 134**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 116 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карар бирде:

1.«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 116 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2025-2027 еллар чорына карата 1,2 процент:

гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналар;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев